| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18 нче апрель 2023 ел** **№ 80**

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советының 2023 елның
20 мартындагы 78 номерлы карарын
гамәлдән чыккан дип тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше нигезендә «Муниципаль хезмәт турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 17 мартындагы 10/13-13 номерлы аңлатмалары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 мартындагы 78 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга: http://mendeleevsk.tatarstan.ru адресы буенча.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылыкны, хокук тәртибен һәм кеше хокукларын саклау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Песәй авыл җирлеге Советы рәисе В.И.Мөхәммәтгалиев